ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 530-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 530-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БУЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 15 феврале
№ 2354-VI ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
Законлылык һәм хокук
тәртибе комитеты
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

2) 5 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системаларында катнашучыларның Татарстан Республикасы территориясендә үзара хезмәттәшлеге (шул исәптән дәүләт юридик бюроларының әлеге түләүсез юридик ярдәм системаларында башка катнашучылар белән үзара хезмәттәшлеге өлешендә) тәртибен Федераль законда билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында билгеләү;

3) 9 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$) Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил;»;

4) 10 статьяда:

а) исемендә «Татарстан Республикасы» сүзләрен «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үз компетенциясе чикләрендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә булыша.»;

5) 12 статьяда:

а) 1 өлешнең $3^2$ пунктында «Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә» сүзләрен «Россия Федерациясе Кораллы көчләренә яисә Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) медик-социаль экспертиза, инвалидларны реабилитацияләү һәм инвалидларны абилитацияләү;»;

6) 17 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм алар ведомствосындагы учреждениеләр, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары, дәүләт юридик бюросы» сүзләрен «әлеге Законның 9 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар халыкка хокукый мәгълүмат җиткерүне һәм аны хокукый гыйлемле итүне Россия Федерациясе норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыра.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 5 пунктының «б» пунтчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 5 пунктының «б» пунтчасы 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын федераль законнарга туры китерүгә юнәлдерелгән.

2023 елның 25 декабрендәге «Аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 639-ФЗ номерлы (23 статья), «Аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 651-ФЗ номерлы (5 статья), «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» Федераль законга һәм «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 661-ФЗ номерлы федераль законнар белән түбәндәгеләр карала:

- Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне һәм Россия Федерациясе субъектларында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрне дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучыларга кертү;
- гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системаларында катнашучыларның Россия Федерациясе субъекты территориясендә үзара хезмәттәшлеге тәртибен билгеләү вәкаләтен кертү;
- дәүләт юридик бюролары һәм адвокатлар тарафыннан инвалидларны абилитацияләү мәсьәләләре буенча консультацияләр бирү юлы белән дәүләт түләүсез юридик ярдәм күрсәтү очраклары исемлеген тулыландыру;
- Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ихтыярый ярдәм күрсәтү турында контракт төзегән гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү.

Югарыда саналган үзгәрешләр «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законы белән җайга салына торган нигезләмәләргә кагыла. Шуңа бәйле рәвештә закон проекты белән республика законына тиешле үзгәрешләр кертелә.

Закон проекты ике статьядан тора.

Закон проектының 1 статьясында 4, 5, 9, 10, 12 һәм 17 статьяларга үзгәрешләр кертү күздә тотыла.

2 статьяда Татарстан Республикасы законының үз көченә керү тәртибе җайга салына: ул закон проектының 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керәчәк 1 статьясындагы 5 пунктының «б» пунтчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керәчәк.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында» 2013 елның 24 маендагы ПУ-444 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.